Нәсыйхәт

Җомга
5
июль
2013 №23

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы

Мөхәррир сүзе

# ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН КИЛ, ГАЗИЗ КУНАГЫБЫЗ!

**Хөрмәтле райондашлар, мөселман кардәшләр! Мамадыш мәдрәсәсе коллективы һәм газетабызның редакциясе исеменнән сезне вә бөтен мөселман кардәшләребезне 2013нче елның Рамазан ае башлану белән ихлас күңелдән тәбрик итәм. Аллаһ Раббыбызга сансыз мактау вә хамде-сәнәләребез булсын. Уникe айның солтаны булган Рамазан-Шәриф аена ирештереп гөнаһлардан пакьланырга, Үзенең ризалыгын казанып, хәерле-изге гамәлләр кылып, күп савапларга ирешергә тагын бер мөмкинлек бирде.**



Фикерләп карасаң, Аллаһының шәригате, кануны бер табибның хөкеменә охшаган. Әгәр шул табибның кушканын үтәсәң, сәламәт һәм бәхетле буласың, үтәмәсәң, көннән-көн зәгыйфьләнә барып, беркөнне һәлак буласың. Шул кануннарның берсе – Рамазан аеның уразасын тоту.

Аллаһы Тәгалә һәрбер гыйбадәтне адәм баласы өчен хикмәтле, файдалы кылган, һәр гыйбадәтнең мәгънәви файдасы белән бергә матди файдасы да бар. Ләкин кеше бер гыйбадәтне матди файдасы өчен дип кылса, Аллаһы аннан ул гамәлне кабул кылмый. Һәрбер гамәл фәкать Аллаһы ризалыгы өчен генә кылынырга тиеш. Ураза тотуның хикмәте, мәгънәви файдасы – тәкъвалыкны арттыру, булмаса – булдыру.

Ураза тоту белән кеше Аллаһы Тәгалә каршында үзенең никадәр зәгыйфь һәм мохтаҗ булуын таный. Шуның белән аның горурлыгы, тәкәбберлеге киселә. Сусау, ачлык авырлыгын татып, фәкыйрь-мескеннәрне искә төшерә. Нәтиҗәдә, күңелендә аларга карата шәфкать, мәрхәмәт хисе уяна. Ураза тоту мөселманнарның ихтыяр көчен ныгыта. Тормыштагы авыр сынаулар алдында үзенә күрә бер әзерлек булып тора. Ураза тотучы кеше Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең кадерен белә башлый. Чөнки күп очракта булган нәрсә кадерләнми, югалгач кына кадере, кыйммәте беленә. Без дә үзебезгә бирелгән нигъмәтләрнең ләззәтен алардан тыелмыйча торып белмибез. Ураза тотып без тәкъвалыкны, сабырлыкны, мәрхәмәтлелекне, шөкер кылуны һәм сәламәтлекне табарбыз. Ләкин, бозык, ялган сүзләр сөйләп, явызлыклар кылып йөрүчеләрнең ач торуларында күп хикмәт табылмас.

**«Әгәр бер кеше ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаса, Аллаһы Тәгалә каршында аның ашамый, эчми торуында файда юк». «Ураза Минем өчен генә тотыла, шуңа күрә аңа (хисапсыз) әҗерне Үзем белеп бирәм». Хәдис кудси.**

Аллаһы Тәгалә башка изгелекләргә ун өлештән алып җиде йөз өлешкәчә булган әҗер-саваплар вәгъдә иткәндә, ураза тотучыларга хисапсыз әҗерләр бирүе уразаның мөселманнар тормышында нинди зур әһәмияткә ия икәнлегенә тагын бер дәлил булып тора.

Шиксез, Раббысының кушканына буйсынып, хәләл нәрсәләрдән баш тарткан кешенең, хәрам нәрсәләрдән баш тартмавы мөмкин түгел. Үзенең ихтыяр көчен ураза тотарга буйсындырган кеше башка сынаулар алдында да бирешмәс.

Аллаһ Раббыбыз кешеләрне, рух һәм тән берлеге буларак, җир йөзендә яратты. Шуңа күрә тәнне дә, рухыбызны да тәрбияләү – безнең бурычыбыз. Тәнне мунча кереп чистартабыз. Рухны бит су кертеп яки мунчага кертеп пакълап булмый. Без рухыбызны гыйбадәт кылып, гыйбадәтләрнең асылы булучы ураза тотып тәрбиялибез дә инде. Кеше хайваннан камил гакыл белән аерыла.

**(Дәвамы 2нче биттә)**

# ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН КИЛ, ГАЗИЗ КУНАГЫБЫЗ!



Белгәнебезчә, хайванның тамагы ачса, ул әйберне вата-җимерә ризыкка омтыла, әмма без, кешеләр буларак, үзебездә ихтыяр көче таба алабыз. Үзебезнең тән генә түгел, рух та икәнлегебезне искә төшерәбез, шулай итеп рухыбызны зурлыйбыз.

Газиз мөселман кардәшләр! Рамазан аен бер кунагыбызны каршылаган кебек каршыласак иде. Без берәр кунагыбызны каршылыйсы булсак, аңа алдан әзерләнә башлыйбыз, йортыбызда тәртип ясыйбыз, җыештырабыз. Шуның шикелле, Рамазан аена да алдан әзерләнергә тиешлебез.

Әлбәттә, ураза тоту көннәре озыная, әмма моның белән, һичшиксез, аның әҗере дә арта. Гыйбрәтле ки, элек әби-бабаларыбыз басуларда, кырларда, ындыр табакларында эшләгәннәр, шул ук вакытта уразаларын да калдырмаганнар. Безнең яшәеш күпкә җиңелрәк: табында ни теләсәң, шул бар, алдынгы техник чаралары кулланып яшибез. Шуны да онытмаска кирәк, җәннәт тә бит бик кыйммәтле, бәһале, тырышмыйча гына, берникадәр мәшәкатьләрне күрмичә генә аңа лаек булып булмый. Рамазан-шәриф аенда Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам Аллаһы тарафыннан җибәрелгән Җәбраил фәрештәдән Коръән-Кәрим дәресләрен ала иде. Шуңа күрә бу ай һәрбер мөселман өчен дәрес ае да булып тора.

Бу айда без фәкыйрьләрнең, ачларның хәлләрен аңлау дәресен үтәбез. Аларга карата күнелләребез йомшара. Гомумән, җир шарында бар халыкның биштән бере фәкыйрьлек хәлендә яшәгән вакытта, мөселман кешесенең күңеле тыныч булырмы?

Бу айда без сабырлык дәресләрен дә алабыз. Күпләребез көн буе төрле гөнаһлар кылмыйча түзәргә өйрәнә, берәүләребез үзләрен гайбәттән тыеп тору дәрәҗәсенә ирешә. Бу зур дәрес түгелме? Һәрнәрсәнең ачкычы булган кебек, җиңүнең дә ачкычы–сабырлык.

Без үзебезнең нәфесебезне җиңәргә тырышабыз. Ә нәфесне фәкать сабырлык белән генә җиңеп була. Аллаһы Тәгалә бу айда хәтта безне хәләл җефетләребездән дә арындырып торып, нәфесебезне кулга алырга өйрәтә.

Пәйгамбәребез әйтте: «Ураза тотучы кеше начар сүзләр әйтмәсен һәм кычкырышмасын. Әгәр берәү аны мыскыл итеп сүксә, яки әйткәләшергә сәбәп эзләсә: «Мин ураза!» – дип әйтсен».

Һәрбер мөселман ураза тотканда үзенең телен, күзләрен һәм башка әгъзаларын Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән сакламаса, аның барлык әҗер-саваплары җилгә очачагын һәм тоткан уразасы бушка булачагын белеп тора. Димәк, акыллы, игътибарлы мөселман бу мөбарәк Рамазан аеның һәрбер мизгелен игелек белән үткәрергә тырыша.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Бу ай мөселманнар арасында ярдәмләшү һәм ризыкның бәрәкәтле вә мул булган аедыр. Кем бу айда бер уразалы кешене ифтар кылдырса, бер кол азат иткән кадәр савап казаныр һәм бөтен гөнаһларының гафу ителүенә сәбәп булыр. Пәйгамбәребезнең иң бөек могҗизасы булган Коръән-Кәрим бу айда иңдерелгәне өчен, Рамазанда изге китабыбызны уку һә аны укып чыгу яки хәтем кылу зур әҗерле гамәлләрдән санала.

Газиз кардәшләребез! Шәриф Рамазан ае башлана мәчетләрдә, тәравихларда, мәҗлесләрдә Аллаһыдан шифалы яңгырларын сорыйк, хәерле, бәрәкәтле тормыш үтеник, илләребезгә хәерле тынычлыклар ялварыйк. Бәлки, Раббыбыз, иншәАллаһ, Рамазан ае, Корьән иңгән ае хөрмәтенә догаларыбызны кабул итәр.

Хөрмәтле мөселманнар! Түземсезлек белән көтеп алынган Рамазан ае да җир шарыбызга аяк баса. Бу вакыйга бер яктан, күңелгә шатлык, икенче яктан, җаваплылык өсти. Шатлык, чөнки Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, җаваплылык, чөнки, билгеле булганча, һәр башланган әйбернең ахыры бар, димәк, безгә күп кенә бүләкләр белән килгән кадерле кунагыбызны озатыр вакытлар да көттермәс. Шуңа күрә үкенечкә калмасын өчен Рамазан ае биргән бик күп кыйммәтле дәресләрне тормышыбызга ашырсак иде. Шушы дәвердә нәфесебезне җиңәргә, күңелне пакьләргә, хайван сыйфатларын җиңәргә өйрәнсәк иде. Әйе, бу айда без бихисап зур дәресләр алабыз. Әмма һәркайсыбыз да дәресебезне гомеребез буе үтәргә тырышсак иде. Чөнки калган 11 ай да Аллаһыныкы. Ул айларда да гөнаһ кылырга рөхсәт юк. Ураза тоту Рамазан белән генә чикләнми, безнең башка айларда да күп нәфел уразаларыбыз бар. Шәүвәл аенда 6 көн, һәр айның уртасында 3 көн, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә һәм гашура уразалары, калган айларда да Коръән-Кәрим уку, һәр ай саен бер хәтем кылу рәсүлебезнең сөннәтеннәндер. Калган айларда да фәкыйрьләрнең ризыкка мохтаҗ булуларын онытмасак иде.

Хөрмәтле районташлар! Рамазан ае безгә юмартлык дәресләрен дә бирмичә калмас. Шунлыктан Раббызның ачуын китерә торган саранлыгыбыздан арынсак иде. Бүгенге көндә мәдрәсә яңа уку елына әзерләнә. Ел дәверенә шәкертләрне ризык белән тәэмин итү, укытучыларга хезмәт хаклары түләү өчен финанс булдыру бик авыр эш. Һәм бу эштә бергә һәм бердәм булсак кына гамәлләребез нәтиҗәле булыр. Мәчет-мәдрәсәләребезне ятим итмик, малларыбызны кызганмыйк, көчебездән килгәнчә гошер һәм фитраларыбыз белән ярдәм итик.

Хөрмәтле кардәшләр! Раббыбыз тоткан уразаларыбызны, кылган изгелекләребезне кабул итсен! Киләчәк Рамазан аен да исәнлектә каршы алып, уразаларны тотарга насыйп итсен! Раббыбыз, тормышларыбызның һәр көнен Рамазан шәриф аендагы кебек бәхетле, чиста һәм ихласлы, ә төннәребезне Кадер кичәләре кебек зекер һәм истигъфарлы итеп үткәрергә насыйп әйләсен.

Раббыбыз барча галәмгә муллык вә сәгадәт насыйп әйләсен!

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**
**ӘЗЕРЛӘДЕ**

# УРАЗАНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ



Галәмнәрнең Раббысының сөеклесе (с. г. ү. с.): **“Ялгыз ашказанына ураза тоттырмагыз. Барча әгъзаларыгызга ураза тоттырыгыз”, –ди.** Ягъни ураза тоткан кеше уразаның өч фарызын (ният кылу, ашау-эчүдән тыелу һәм якынлык кылудан саклану) үтәгән кебек теләсә кайсы әгъза белән бәйләнгән хәрам, мәкруһ һәм һәммә әдәпсез гамәлләрдән тыелырга тиеш. Без, мохтаҗларга ярдәм, олыларга хөрмәт һәм кечкенәләргә шәфкать вә мәрхәмәт күрсәтергә тиешбез. Рамазан ае безнең өчен губудият (ай буе гыйбадәт хәлендә) ае, ягъни безнең һәр башкарган гамәлдән Хак Сөбханәһү үә Тәгалә разый булуы һәм Аллаһы сиңа ни эшләсә дә, син Аллаһыдан разый бул. Инде менә шушы таләпләрне ихлас күңелдән үтәсәк, барча гөнаһлардан арынырга мөмкинлек туа. Нур йөзле Аллаһ Рәсүле бер хәдисендә әйтә: **“Рамазан аенда Аллаһының әҗер-савапларын өмет итеп ураза тотучының үткәндәге барлык гөнаһлары гафу ителәчәк”.**

Уразаның фазыйләтләре турында галимнәребезнең хезмәтләре күп булуга карамастан, аның әле чын мәгънәсен Бөек Хак Аллаһыдан башка беркем дә белми. Шулай да, Пәйгамбәрләр солтаны (с. г. ү. с.) әйтүе буенча фазыйләтләрнең безнең фараз буенча иң зурысы: **“Рамазан аенда ураза тотучының тоткан уразасы кабул булса, анадан яңа туган бала шикелле гөнаһсыз булып калыр”.**

Бүгенге көнне кешене өйрәнә яки аның белән нинди дә булса сорау белән бәйләнгән фәннәр (гыйльме рух, педагогика, гигиена һәм тыйб, диететика, ислам дине галимнәренең өйрәтүләре, җәмгыять белән бәйле фәннәр һ.б.) нигезендә Рамазан аеның фазыйләтләрен өйрәнү, ачыклау һәм тормышыбызда киң куллану безгә мөмкинлек бирә, яшәү рәвешебезне пакьләндерүдә һәм җәнаби Хак Тәгаләнең ризалыгын өмет итүгә. Мөмкинлегебезне исәпкә алып югарыда санап кителгән фәннәр нигезендә дәлилләнгән һәм зур әһәмияткә ия фазыйләтләргә генә тукталып китәргә булдык.

Беренче чиратта ислам дине галимнәренең өйрәтүләре (тезислары) :

Ураза тоткан мөселманнар каберләреннән хуш исләр белән кубарылырлар. Фәрештәләр аларны төрле тәгамнәр һәм эчемлекләр белән сыйларлар;

Әгәр мөселман Рамазан ае кергәне өчен шатланса, үтеп китүе өчен кайгырса, Аллаһы Раббел-Гыйззә ул мөселманның тәнен тәмуг утыннан хәрам кылыр;

Рамазан аенда ураза хәлендә җан тәслим кылган мөселман оҗмахлы булыр;

Галимнәр: “Оҗмахны 4 төрле төркемгә гашыйк”,–диләр.

1)Коръән укучыга.

2) Бу изге айда телне гайбәттән, сүз йөртүдән һәм башка ярамас нәрсәләрдән сакланган кешегә гашыйк.

3) Бу шәриф айда ачларга ризык биргән кешегә гашыйк.

4) Рамазан аенда ихлас белән ураза тотучыга гашыйк.

Ислам динендә гыйбадәтләргә 10 кат белән 700 кат арасында савап бар дип өйрәтәләр. Ләкин уразаның савабын чиксез диләр. Хәлим вә Кәрим булган Аллаһы Тәгалә: **“Адәм баласының, уразадан башка һәр эше (гыйбадәте) үзе өчендер. Ләкин ураза минем өчен. Аның савабын (әҗерен) мин бирәчәкмен”** , - ди.

Бу айның соңгы 10 көненнән бер киче – Кадер киче була. Ул кичәне Аллаһ Раббыбыз “1000 айдан да хәерлерәк”, –ди. Ягъни, Коръән иңә башлау хөрмәтенә соңгы 10 көннең һәр кичен үткәрик изге ниятләрдән булган гамәлләр белән генә...

Хәзерге заман педагогикасы да гыйльме рух нигезендә Рамазан аеның яшьләрне тәрбияләүдә иң үтемле вакыт булуын кире кага алмый. Аң-белем ала торган бу мөбарәк айны Аллаһ Илчесе Мөхәммәд галәйһиссәлам сүзе белән әйтсәк “мәдрәсә ае”. Шайтаннар чылбырлар белән богауланып куела торган бу шәриф айда безгә бөтен мәгънәсе белән үзебезнең кем икәнебезне ачыкларга була. Ә инде ураза аенда нәфесебезне тиешле тәртиптә “йөгәнләргә” (тәрбияләргә) өйрәнсәк, бу безгә башка вакытта да (ураза аеннан тыш) шайтанга каршы безнең бик яхшы калкан була. Бу турыда Галәмнәргә мәрхәмәт буларак җибәрелгән Пәйгамбәребезнең (с. г. в. с.) хәдисләрендә әйтелә: **“Ураза – кешене начар эшләрдән саклаучы бер калкандыр” һәм бер сугышта кяферләрне җиңеп кайткач: “Хәзер кечкенә сугышны җиңдек. Моннан соң зур сугышны да җиңәргә тырышыгыз”,**–дигән. Аптырап калган халыкка ул: “Иң зур сугыш – кешенең үз нәфесенә каршы, ягъни эчендәге начар ният вә теләкләренә каршы сугыштыр”,–дип җавап биргән. Гыйльме рух фәне өйрәтүе буенча нәфесне җиңәр өчен бездә ихтыяр көче тиешле дәрәҗәдә тәрбияләнгән булырга тиеш. Ә ихтыяр көче, ягъни эчке (психик) энергияң белән физик хәл һәм көчеңне сиңа бирелгән гамәлне башкарырга туплау дәрәҗәсе төрле алымнар белән тәрбияләнә: сабырлык, тугрылык, хәбиблек, тәкъвалык һәм изгелек сыйфатлары тәрбияләү аркылы. Кешелек дөньясының мактанычы Пәйгамбәребез (с. г. в. с.) әйтүе буенча: **“Һәр нәрсәнең бер зәкате бар. Гәүдәнең зәкате–уразадыр. Ураза–сабырның яртысы”**,–дигән. Ә тугрылыкны Аллаһ Раббыбыз фарыз кылган: “Әй, мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз үә тугрылык белән бергә булыгыз!” (“Тәүбә” сүрәсе, 6-7 нче аятьләр); кечкенә максатлардан катлаулы ниятләргә омтылу аркылы, гыйльме рух фәне өйрәтүе буенча үзара индукция алымы белән һ.б. Иншәаллаһ! Киләсе язмаларымның берсендә бу сорауга тирәнрәк тукталырмын дип уйлыйм.

Ураза безнең нерв системасын җайга сала, дәвалый һәм ныгыта. Нәтиҗәдә, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән безнең организм куәтләнеп кенә калмый, ә тиешле күләмдә җан азыгы да ала.

Уразаның мөһим фазыйләтләре хакында диететика, гигиена һәм тыйб фәннәре түбәндәгеләрне (тезислар формасында) җиткерә:

Ураза безнең иммунитетны (авыруларга бирешмәү сәләтен) ныгыта. Ягъни кандагы лимфоцитларның эшчәнлеге ун тапкыр үсә;

Эчке органнарда “таш” барлыкка килү процессы туктый;

Һәр тәүлек саен бавыр алты сәгать ял итә. Йөрәктән кала бавыр иң авыр вазифаны үтәүче әгъзалардан берсе буларак, тиешле тәртиптә уразадан тыш ял итә алмый икән;

Бу айда организмда яраксыз майлар эри, аннан “биошлак” һәм авыр тозлар чыга. Кеше яшәрә, яңа көч ала.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, тоткан уразабыз ахирәт көнендә Бөек тәхетнең иясе Раббым алдында безнең шәфәгатьчеләрнең берсе булу мөмкинлеген истә тотып, уразабызны ихлас күңелдән, җиренә җиткереп һәрберебезгә тотарга язсын!

Ураза аеның соңгы 10 көнендә, ягъни уттан котылу көннәрендә тәравих намазларыбызны да калдырмыйк!

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ, мәдрәсәнең 2 курс шәкерте, гер күтәрү буенча халыкара спорт остасы.**

# УКЫДЫК БЕЗ МӘДРӘСӘДӘ

**Яраткан шагыйребез Габдулла Тукайның бу шигыре "Аңламадык бернәрсә дә" дип дәвам иткәнен һәркайсыбыз яхшы белә.**



Чыгарылыш–2013

Тик әлеге шигъри юллар Мамадыш мәдрәсәсен тәмамлаучыларга һәм анда укучыларга һич тә кагылмый. Шәһәребездә мәдрәсә ачылганга биш ел вакыт узып та киткән инде. Кемдер шушы вакытны ничек уздырырга белми аптырагандыр, кайберәүләр бер дә файдасызга үткәргәндер. Ә менә биш ел элек Мамадыш мәдрәсәсенә гыйлем алырга килгән шәкертләр, һич тә икеләнмичә, "безнең бу еллар заяга узмады" дип әйтә ала. "Тормышта үзеңне кая куярга белмәгән чаклар бик күп була. Кайчак, хәтта, кесәң тулы акча булса да күңелеңә тынычлык таба алмавың бар. Безнең Ислам дине теләсә кайсы сорауга җавап табарга ярдәм итә. Бик авыр чакларда да адәм баласы Аллаһ ярдәменә өмет итә ала. Ә аның ярдәме белән дини гыйлемнәр үзләштерергә насыйп булган икән, димәк, сез – Раббыбызның яраткан коллары. Мондый мөмкинлекне Аллаһы Тәгалә бары сөекле бәндәләремә генә бирермен, дигән бит. Аллаһ ризалыгы өчен дини гыйлемнәрне тупларга ярдәм иткән мөгаллимнәргә зур рәхмәт. Инде хәзер үзегезгә җаваплы бурыч йөкләнә, сез дә үзегез белгәннәрне башкаларга, бигрәк тә балаларга җиткерергә тиеш",–диләр мөгаллимнәр. Иң хөрле сүз–Раббыбыз сүзе. Шуңа күрә бәйрәмдә Коръән аятьләре яңгыравы гаҗәп түгел. Аларны бик тә моңлы итеп мәдрәсәнең директоры Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин укыды. Аннан соң мәдрәсәдә укучылар эчтәлекле чыгышлар ясадылар. "Бүген бездә чын бәйрәм. Башкалар үрнәк, гыйбрәт алсын өчен, мондый сөенечле хәбәрләрне Пәйгамбәребез башкаларга да таратырга кушты. Моннан биш ел элек Мамадышта мәдрәсә ачылу үзе бер сөенеч булган иде. Безнеке кебек заманча мәдрәсә республика районнарында, бездән кала, Әгерҗедә, Буада һәм Теләчедә генә бар. Мәдрәсәне тәмамлаучы шәкертләребез мондый гыйлем учагы булдыруга зур көч куйганнарга, башка игелек иясләренә күңелләреннән рәхмәт укыйдыр бүген", – дип уйладым чыгышлар, вәгазьләр тыңлаганда. Без, мәдрәсәдә дүрт ел укып, башлангыч дини гыйлем алдык. Бу – һәрберебез өчен фарыз. Чөнки һәр мөселман намаз, Коръән укый белергә тиеш. Тик гыйлемле булуыбыз "мин күпне беләм" дип күкрәк киереп йөрү мөмкинлеген бирми. Болай фикерләүчеләр Аллаһы Тәгаләнең ачуын гына чыгарачак. Тәкәбберлек – мөселманга хас сыйфат түгел, Аллаһ сакласын. Дөреслектә, иң гыйлемлесе – Иблис. Тик ул гыйлемнәрен дөрес итеп файдалана белми. Гыйлем алу – бер нәрсә, аны дөрес итеп файдалана да белергә кирәк, дип уйлыйм мин.

Үземнең ничә тапкыр талпынып та, "булдыра алмам" дип, бу уемнан кире кайтканым бар. Тик бу шәкертләргә үҗәтлек тә, сабырлык та, тырышлык та бердәй хас, күрәсең. Күпчелеге дини гыйлемнәрне яхшы билгеләренә үзләштереп кенә калмыйча, имтиханнарны да бик уңышлы тапшырып чыкканнар. Кулыма мондый хөрмәтле документ алганым юк иде әле. Шәкертләр, үз чиратларында, аларга белем биргән Венера абыстай, Эльвира ханымнарга, Габдрахман, Ранил, Ирек, Илнур, Нурислам, Илнар хәзрәтләргә олы рәхмәтләрен җиткерделәр. Аллаһы Тәгаләнең: "Минем сүземне адәм балаларына җиткерүчедән дә сөекмле кеше юк", дигән сүзләре бар. Бу мөгаллимнәребез дә вакытларын, сабырлыкларын кызганмыйча башкаларга белем бирү бәрабәренә олы саваплы булырлар, иншаллаһ. "Белем алу бишектән алып ләхеткә кадәр тиеш",–дигән Пәйгамбәребез. Шәһадәтнамә алучылар арасында да төрле яшьтәгеләр бар иде. Әле мәктәптә укый торган яшь өч кыз булуы сөендерә. Авыллардан "попутка"ларда мәдрәсәгә йөрү җиңел булмагандыр. "Укырга баргандa да бервакытта да машина көтеп торганыбыз булмады. Игелекле бәндәләр очрап кына торды", – диделәр алар. Мамадыш мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләрнең алган белемнәр белән генә чикләнергә исәпләре юк. Белем алуларын кайда гына дәвам итсәләр дә, тел ачкычы бирсен аларга Ходай!

ФИРАЯ МИНГАЛИЕВА

**АЛСУ ФАЗЫЛРАХМАНОВА, икенче санлы лицейның унынчы сыйныф укучысы:**



–Без өч сыйныфташ, дус кызлар–мин, Альбина Ганиева, Чулпан Вәлиева **(рәсемдә уңнан сулга)** белән укырга бергә йөрдек. Үзебезгә файдалы күп нәрсәләр белдек. Безгә ошый. Өйдә дә ислам дине буенча яшибез. Бабам ике тапкыр хаҗга барды. Гыйлем алуыбызны дәвам итәргә уйлыйбыз.

**НУРЗИЛӘ НӘКЫЙПОВА, мәгариф ветераны**

–Гомер буе мәгариф системасында эшләп, пенсиягә чыгуга мәдрәсәгә аяк бастым. Ул гарәп алфавитын бер дә танырбыз сыман тоелмаган иде. Әлифне таяк дип тә белми идек бит. Укытучыларыбыз Венера Яруллина, Ранил Талипов, Илнур Зыятдиновка түземлелекләре, сабырлыклары өчен олы рәхмәтләребез. Биредә тормыш дәресләре бирәләр, тулы канлы тормыш белән яшәргә өйрәтәләр. Мамадыш халкы хикмәтнең нидә икәнен тизрәк аңлап, мәдрәсәгә агылсын иде.

# ИЮЛЬ аена намаз вакыты

| КӨН САНЫ | КӨН ИСЕМЕ | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | КОЯШ ЧЫГУ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ДҮШ | 2.33 | 4.03 | 13.00 | 18.41 | 21.31 | 23.01 |
| 2 | СИШ | 2.34 | 4.04 | 13.00 | 18.41 | 21.31 | 23.01 |
| 3 | ЧӘРШ | 2.35 | 4.05 | 13.00 | 18.41 | 21.30 | 23.00 |
| 4 | ПӘНҖ | 2.36 | 4.06 | 13.00 | 18.41 | 21.30 | 23.00 |
| 5 | ҖОМ | 2.37 | 4.07 | 13.00 | 18.40 | 21.29 | 22.59 |
| 6 | ШИМ | 2.38 | 4.08 | 13.00 | 18.39 | 21.28 | 22.58 |
| 7 | ЯКШ | 2.39 | 4.09 | 13.00 | 18.38 | 21.27 | 22.57 |
| 8 | ДҮШ | 2.40 | 4.10 | 13.00 | 18.38 | 21.26 | 22.56 |
| 9 | СИШ | 2.41 | 4.11 | 13.00 | 18.37 | 21.25 | 22.55 |
| 10 | ЧӘРШ | 2.42 | 4.12 | 13.00 | 18.37 | 21.24 | 22.54 |
| 11 | ПӘНҖ | 2.43 | 4.13 | 13.00 | 18.36 | 21.23 | 22.53 |
| 12 | ҖОМ | 2.45 | 4.15 | 13.00 | 18.35 | 21.22 | 22.52 |
| 13 | ШИМ | 2.46 | 4.16 | 13.00 | 18.34 | 21.20 | 22.50 |
| 14 | ЯКШ | 2.48 | 4.18 | 13.00 | 18.33 | 21.19 | 22.49 |
| 15 | ДҮШ | 2.49 | 4.19 | 13.00 | 18.32 | 21.18 | 22.48 |
| 16 | СИШ | 2.51 | 4.21 | 13.00 | 18.32 | 21.17 | 22.47 |
| 17 | ЧӘРШ | 2.52 | 4.22 | 13.00 | 18.31 | 21.15 | 22.45 |
| 18 | ПӘНҖ | 2.54 | 4.24 | 13.00 | 18.30 | 21.14 | 22.44 |
| 19 | ҖОМ | 2.55 | 4.25 | 13.00 | 18.29 | 21.12 | 22.42 |
| 20 | ШИМ | 2.57 | 4.27 | 13.00 | 18.28 | 21.11 | 22.41 |
| 21 | ЯКШ | 2.58 | 4.28 | 13.00 | 18.27 | 21.09 | 22.39 |
| 22 | ДҮШ | 3.00 | 4.30 | 13.00 | 18.26 | 21.08 | 22.38 |
| 23 | СИШ | 3.02 | 4.32 | 13.00 | 18.25 | 21.06 | 22.36 |
| 24 | ЧӘРШ | 3.03 | 4.33 | 13.00 | 18.23 | 21.04 | 22.34 |
| 25 | ПӘНҖ | 3.05 | 4.35 | 13.00 | 18.22 | 21.03 | 22.33 |
| 26 | ҖОМ | 3.07 | 4.37 | 13.00 | 18.21 | 21.01 | 22.31 |
| 27 | ШИМ | 3.09 | 4.39 | 13.00 | 18.20 | 20.59 | 22.29 |
| 28 | ЯКШ | 3.10 | 4.40 | 13.00 | 18.19 | 20.57 | 22.27 |
| 29 | ДҮШ | 3.12 | 4.42 | 13.00 | 18.18 | 20.55 | 22.25 |
| 30 | СИШ | 3.14 | 4.44 | 13.00 | 18.17 | 20.54 | 22.24 |
| 31 | ЧӘРШ | 3.16 | 4.46 | 13.00 | 18.16 | 20.52 | 22.22 |

**Игътибар**

## Ифтар мәҗлесләрен үткәрүчеләргә

**МӨСЕЛМАН КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ!** Рамазан аенда ифтар (авыз ачтыру) мәҗлесләрен үткәрергә теләүчеләр Мамадыш мәдрәсәсенә мөрәҗәгать итә алалар. Белешмәләр өчен телефон: 89172802391

## Ярдәм итик

**Мәдрәсә бинасында яңа уку елына әзерлек бара.** Уку җиһазлары ремонтлана, буяу һәм чистарту, уку бүлмәләрен төзекләндерү эшләре алып барыла. Газиз кардәшләр! Бу изге эштә бергәләшеп катнашыйк. Бигрәк тә Рамазан аенда малларыбызны һәм көчләребезне кызганмыйк. Мөмкинлегебез булганча мәдрәсәбезгә ярдәм итик.

## Кабул итү комиссиясе эшли

**Мәдрәсәгә укырга керергә теләүчеләр өчен кабул итү комиссиясе эшли.** Биредә уку-укытуга кагылган сорауларга җавап бирәләр, документларны, белешмәләрне кабул итәләр.

**Белешмәләр өчен телефон: 89172802391, 89093148644**

# САБЫРЛЫКНЫҢ КҮРКӘМ ӨЛГЕСЕ

Нинди сихри көч бар бу табигатьтә?! Без, аның балалары көн саен нindидер вактөяк эш белән чабып, тирәюнебездәге матурлыкны, хозур-гүзәллекне күрмибез дә, аңа сокланмыйбыз да бит, чөнки вакытыбыз юк. Аллаһы Тәгаләбезнең ел әйләнәсе туып торган һәр якты көнен "шулай тиеш" дип кенә кабул итәбез, Раббыбызга чын күңелдән рәхмәт әйтергә дә онытабыз. Без Ходай Тәгаләне инде үзебезне аңлар, кызганыр кешебез бөтенләй дә калмагач кына искә төшерәбез шул. Ә бит аны шатлыклы-куанычлы вакытларыбызда бигрәк тә истә тотарга кирәк. Чөнки без сөенечле мизгелләребез белән бары тик үзебезне якты дөнья хозурына китергән, юктан бар иткән Аллаһыбызга бурычлыбыз.

Әйе, Ходайның кодрәте киң. Ул үзенең бәндәләре белән ни теләсә– шуны эшли ала. Бәләкәй генә җилдән башланган зур өермәнең үз юртасына эләккәннәрне кайда, кайчан, ни кыяфәттә илтеп ташласын бер Аллаһы гына белә шул! Хак Тәгалә адәм баласына дөньялыкта ачысын да, төчесен дә тигез итеп татып карата. Мин дә үз гомеремдә төрлесен күрдем. Егылган-торган, елаган-көлгән, ялгышкан-хаталанган вакытларым күп булды. Нишләмәк кирәк, гомер буе, хәтта олыгаеп барган көнебездә дә, кылабыз шул хилафлыкларны. Бәндә хатадан хали түгел, дип юкка әйтмиләр. Соңгы ике елда көчле тетрәнүләр – Аллаһы Тәгаләнең зур сынауларын кичерергә туры килде миңа. Гадәттә, кеше дин юлына нәкъ менә үз тормышында килеп чыккан стресслардан соң баса, дигән сүз, күрәсең, чыннан да дөрестер, хактыр. Үземә иң авыр чакта эзләп таптым мин Мөнирәне. "Нәсыйхәт" дигән дини газетада аның "Сабырлык" дип аталган язмасын укыдым. Берничә ел элек бер йортта яшәгән күршем бит ул минем! Мәкаләне кат-кат укыдым, бик шатландым. Аллаһының рәхмәтедер, көннәрнең берендә уртанчы улы Рәмис машинасы белән килеп туктады йортыбыз янына. Ул баладан әнисенең телефон номерын сорадым. Әнә шул көннән башланды безнең яңадан "танышуыбыз", якын дуслыгыбыз. "Инде түзәрлегем калмады!" – дип, башымны ташларга орырдай чакта да мине сабырлыкка, түзем-чыдам булырга өндәгән Мөнирә! Үзе дә күп газап-сынаулар кичергән хатын-кыз буларак, хәлемә кереп, җылы сүзләре белән юатты, алга таба яшәүгә көч бирде. Моңа Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә чын күңеленнән инанган, нык иманлы адәм баласы гына сәләтледер, дисәм, һич ялгышмамдыр. Мин үземне Мөнирә алдында гомергә бурычлымын, дип исәплим. Кеше психикасы – бик нечкә нәрсә, ул үзенә саксыз кагылганны яратмый да, күтәрми дә, кичерми дә! Акылдан язганнар азмы бу дөньяда көчле кичерешләрдән?! Раббым мине ярдәменнән ташламады. Мөнирәне мине аңлаучым, аклаучым, яклаучым, саклаучым итте, ак күңелле фәрештәмә әверелде. Аның изге теләкләре, үгет-нәсыйхәтләре белән мин, башыма ак яулык ябып, мәдрәсә ишеген ачып кердем, Габдрахман хәзрәтнең булмәсенә үтеп, киләсе уку елында беренче курска укырга килергә теләгем булуны әйттем. Ак-пакь, изге, олы җанлы дускаем, шулай итеп, мине әкрен генә, иплəп-җайлап кына, дин юлына бастырды, намаз-дога уку тәртипләрен өйрәтә башлады, дини китаплар укудан калебемә тынычлык, күңелемә



сабырлык иңәсен төшендерде... Аллаһы боерса, ак яулыгымны да моннан ары башымнан салмамдыр. Мөэмин-мөселманнарның изге, Олуг Китабы булган Коръән-Кәримне кулыма алырга этәргән кеше дә – Мөнирә. Хак Тәгаләмнең рәхим-шәфкате белән шулай ук мәдрәсәдә сатып алдым мин Аны! "Бу дөньяны ташлап китәргә беркайчан да соң түгел, дустым. Дөнья бит бик матур, иркен, киң, яшик әле рәхәтләнеп, Ходай биргән кадәр гомерне бәрәкәт белән",–дип әйтүче дә син, ахирәткәем. Аллаһыма шөкер, исән-сау булырга язсын, киләсе уку елында мин дә тиздән синең белән бергә изгелеккә, сабырлыкка, нык иманлы булырга өйрәтүче урында – мәдрәсәдә, укый башлаячакмын. Азмы-күпме булган дөньяви белемнәремә дини гыйлем дә өстәлсә, һич тә начар булмас, дип уйлыйм, иншәаллаh! Форсаттан файдаланып, шәһәрдәшләрем, якташларымны да мәдрәсә ишекләрен ачып керергә, андагы мөгаллимнәрдән гыйлем алырга чакырам. Үкенмәбез, Аллаһы боерса. Дин безне начарлыкка өндәми бит, бары яхшы гамәлләр кылырга гына өйрәтә.

Мөнирә! Син мине инде өлкәнәеп барган көнемдә тормышка башка күзлектән карарга, яңача яши башларга өйрәттең. "Күз яшьләре үткәннәрне юа алмыйлар. Алар кешенең йөзенә яңа сырлар гына сала. Ходайның кодрәте киң. Ул таякны ике башлы иткән. Бүген сине нахакка рәнҗетсәләр, иртәгә үзеңне газапларга, яну-көюләргә дучар иткән, хәтереңне калдырган бәндәләргә җәзасын бирәчәк Хак Тәгалә. Сабырлык, бары тик сабырлык белән генә җиңәргә була авырлыкларны",–дигән сүзләрең дә йөрәккә шифа бит. Мин шулай ук: "Теге дөньяга, ягъни ахирәткә дә, китәреңә ике генә көн калгач, әзерләнмиләр. Җир йөзендә, фани дөньяда, кешеләрчә, берәүгә дә рәнҗетмичә-кыерсытмыйча, һичкемгә ачу-үпкә сакламыйча, хәрамга кермичә, юмарт булып яшәү – шушы буладыр инде ул бакыйлыкка күчүгә әзерләнү. Барысы да Раббыбыз кулында, кайчан алып китәсе билгеле түгел, шуңа күрә кеше үлемгә һәрвакыт әзер булырга тиеш. Кәфенлегеңне алдан кайгырт, ул үлгәнеңне теләп ятмый, бәлки, гомер теләп ята",–дигән фикерләрең белән дә килешәм.

Икебез дә шигырьләр яратабыз, матур, тирән эчтәлекле шигырьләрне укып, моңсуланып, елап та алабыз, фикерләр алышабыз. Әйе, моң-сагышлы кеше, һичшиксез, җыр, шигырь ярата.

Мин үзем дә язгалыйм. Дустым Мөнирә кеше язганның бәһасын белә. Ул аларны җаны, күңеле, йөрәге белән тоеп, бөтен нечкәлекләрен аңларга тырышып укый. Кыскасы өч бала (ике ул, бер кыз) әнисе, лаеклы ялда булуына карамастан, актив тормыш белән яши. Дөньяның әчесен-төчесен җитәрлек татыган, шул исәптән, ирен югалту кайгысын да кичергән ханым: "Бүгенге көнемнән бик канәгатьмен, Аллага шөкер",–ди. Миңа синнән үрнәк алып, сабырлыкка армый-талмый өйрәнергә дә өйрәнергә генә кала, дускаем. Туган көнең котлы, мөбарәк булсын. Ходай сиңа бәрәкәтле гомер, җан тынычлыгы, куанычлы-шатлыклы, яктыҗылы көннәр, иминлек, ныклы саулык-сәламәтлек бирсен. Мине якын күрүеңә шатмын. Һәркемгә дә эләгә торган бәхет түгел бит әле ул – синдәй ахирәтең булу.

**Иң изге, матур теләкләр белән, чын дустың.**

# СОРАУ СЕЗДƏН, ҖАВАП–БЕЗДƏН

**–Ни сəбəпле кайбер җирлəрдə уразаны бер көнгə иртəрəк, яки соңрак тота башлыйлар?**

–Чөнки җир түгəрəк һəм əйлəнə. Кояш та, ай да кайбер җирлəрдə иртəрəк чыга, җиренə күрə үз вакыты куела.

Пəйгамбəр Мухаммəд (С.Г.В.): "Яңа айны күрү белəн ураза тота башлагыз һəм яңа ай күрү белəн ураза тотуны бетерегез. Əгəр болытлы булса, күренмəсə, айның утыз көнен санап башлагыз", – дигəн. ( Бу хəдис сахих эль-Бухари һəм Мөслимнең хəдислəр җыентыкларында китерелə)

Һəр регионда мөселман җитəкчелəре үзлəренең регионнарына карата Рамазан аеның башлануын билгелəп карар кылалар. Аллаһка шөкер, Россия илендəге астрономия фəне яңа айның кайчан чыкканын белердəй дəрəҗəдə. Рамазан ае башланганчы, яңа ай тууының киче шиксез билгеле була. Шуңа күрə, бу сорауда, иң яхшысы, дини җитəкчелəребезнең карарларын кабул итү.

**–Белə торып уразаңны бозсаң нишлəргə?**

–Ураза вакытында( Көндез ашау, эчү, яки хатының белəн якынлык кылу ярамас. Рамазан уразасын белə торып бозган кеше шул гөнаһысы өчен ике ай тоташ ураза тотарга тиешле була. (Рамазан аеның бер көненең уразасын бозган өчен ике ай ураза, ягъни 60 көн түлəп, тагы да 1 көн казасын тотарга кирəк була. Бу 61 көн уразаны Рамазан ае беткəч кенə тотарга. Гаед көннəр элəгергə тиеш түгел. Əгəр дə ике ай уразасын тотканда бер көн тотылмый калса, яңадан башларга кирəк була. Хатыннар, айлык күрем вакытларында ураза тотмаслар, күремнəр бетү белəн шул ике айлык уразаны дəвам гына итəрлəр. Көннəрнең саны онытылса, уразаны яңадан башлау кирəкмəс)

Əгəр кеше хасталык сəбəпле ике ай тотарга көче җитмəсə, алтмыш мескенне ашатырга тиешле була. Бер мескен бер көнлек аш хакыннан чыгып ашатылырга тиеш.

Хатыны белəн якынлык кылган ир вə хатын, икесе дə, уразаларын бозганнары өчен ике ай ураза, яки мескеннəрне ашату белəн түлəрлəр.

Əгəр алар бу эшлəрен ураза икəннəрен онытып яки белмичə эшлəгəн булсалар, ике айлык ураза тоту вə мескеннəрне ашату кирəкмəс.

**–Ураза вакытында, көндез йоклаганда төшлəнеп госелең бозылса, ураза бозыламы?**

–Ураза бозылмый. Госел коенып уразаны дəвам итəсең.

**–Яз вакытларындагы Рамазан аеның казага калынган көннəрен кыш вакытында тотсаң ярыймы?**

–Казага калган уразаларны Корбан вə Ураза бəйрəмнəреннəн башка нинди көнне тотсаң да дөрес санала. Җəй көннəрендə ураза тотарга авыр булса, кыш көннəрендə тоту мөмкин.

**–Хасталык, яки башка кирəклек туып, ураза вакытында борын эченə дару салу ярыймы?**

–Борын эченə салырга да, тамакка дару чəчрəтергə дə ярамый. Дару тамактан ашказанына китеп уразаны бозар.

**–Əгəр тота алмаган уразалары булып, кеше үлеп китсə, аның балаларына, я туганнарына ни эшлəү кирəк?**

– Əгəр кеше тере, сау-сəламəт вакытында ураза тотучылардан булып, хасталык, я картлык сəбəпле уразасының берничə көне генə тотылмыйча вафат иткəн булса, аның өчен фидия сəдəкасын бирү хəерлерəк. Фидия сəдəкасы мəетнең тере вакытта бер мəртəбə ашавының бəясеннəн чыгып санала.

Мөселман кеше үзе үлгəнче калган туганнарына, я якыннарына васыятендə, ничə көн тота алмаган уразалары өчен фидия садакасы бирергə əйтеп калдыру, əлбəттə, хəерлерəктер. Фидия садакасын мəрхүм үзе калдырмаган булса, туганнары үзлəренең малларыннан аның исеменнəн фидия садакасын бирə алалар.

Əгəр дə кешенең мөмкинлеклəре булып та, уразага тиешле игътибар бирмичə үлеп киткəн булса, туганнарыннан берсе аның тотмаган уразаларын тотар, яки тотмаган бер көне өчен бер мескенне ашатыр.

Пəйгамбəр Мөхəммəд (С.Г.В.) əйткəн: "Əгəр кем булса тотмаган уразасы була торып үлеп китсə, туганнары аның өчен ураза тотсын", – дигəн.

**–Ураза тотар өчен ничек дөрес ниятлəргə? Бармы аның нинди дə булса догалары?**

–Рамазан аенда ураза тотарга ниятлəгəн кеше, таң атканчы ашап, эчкəннəн соң шул сүзлəрне əйтеп ураза тотарга керешер: "Нəвəйту əн əсумə саумə шəһри рамадан минəл фəҗри илəл мəгъриби халисəн лиллəһи тəгалə".

Тəрҗемəсе: "Аллаһ ризалыгы өчен таң атудан алып, кояш батканчыга кадəр Рамазан аеның уразасын тотарга ниятлəдем". (Бу сүзлəрне үз телеңдə əйтсəң дə дөрес санала.)

Əгəр кеше ниятлəргə онытса, я сəхəргə тора алмаса, шул көнне ураза тотуы дөрес саналыр, əмма сəхəргə торган өчен бирелə торган саваптан мəхрүм калыр.

Кояш баткач авызыңа аш, я су кабып уразаңны ачканнан соң шул дога укылыр: "Аллахуммə лəкə сумту вə бикə əмəнту вə галəйкə тəвəккəлту вə галə ризкикə əфтəрту. Фəгъфир ли я Гаффəру мə каддəмту вə мə аххарту".

Тəрҗемəсе: "Йə раббым! Синең ризалыгыңны өметлəнеп уразамны тоттым, Синə ышандым, Синə бирелдем, Синең ризыгың белəн ифтар кылдым. Гафу ит мине йə Гаффəр! Кылган вə кылачак хаталарым өчен".

**–Рамазан аенда ризыклануга багышланган нинди дə булса тəкъдимнəр бармы?**

–Уразаны тотучы кешегə көч бирүдə кулланыла торган 3 тəҗрибə бар: 1) ашаганда күп эчмəскə, ашказаны согын сыеклатмаска, ризык кулланып, 40-60 минут узгач кына эчəргə), 2) сəхəр вакытында азыкны куллану, 3) көндез йоклап алырга (13.00 сəгать белəн 16.00 арасында 20-40. Кичке авыз ачу вакытында беренче эш итеп су эчəргə һəм берничə хөрмə ашарга тəкъдим ителə. Беренче итеп су эчү ашказаны-эчəклəрне юдырырга ярдəм итə. Сүз уңаеннан, ач карынга җылы су эчү файдалы. Аңа бераз бал да кушып җибəрсəгез була. Хəдистə ифтар вакытында ризык кабул иткəч, аны сыеклату белəн мавыгырга тəкъдим ителми. Бер үк вакытта күп итеп ашау һəм эчү нəтиҗəсендə ашказанында ризыкны эшкəртү кыенлаша (ашказаны согы сыеклана), бу исə ризыкның эшкəртелеп бетмəвенə китерə, сару кайный башлый. Ураза вакытында бу кайбер кыенлыклар китереп чыгара: кичтəн кабул ителгəн ризык эшкəртелеп бетми, иртəнге якта кеше йə бөтенлəй ашамый, чөнки ачыкмаган була, ашаса, инде ризык өстенə ризык кабул иткəн булып чыга. Ə бу исə көтелгəн нəтиҗəгə китерми.

Мөселманнар кич белəн һəм иртəнге якта, ягъни авыз ачканда, сəхəр вакытында артык ризык кулланудан саклансыннар иде. Кызганыч ки, иманнары ныгып җитмəгəн кайберəүлəр ачлыктан куркып калып, күп ризык ашыйлар. Бу аларга көн дəвамында күтəренке кəефне сакларга булышыр, дип уйлап ялгышалар. Организмына күп ризык керткəн кеше үзе өчен гадəти булмаган, кыен хəлдə кала: бихисап авыр ризыкны эшкəртү өчен аның бөтен көндез тупланган энергиясе китə, шуңа күрə икенче көнне андый затлар йокылы-уяулы, арган кыяфəтле, «Аллаһ ризалыгы хакына үзүзен интектерүче»гə əйлəнə. Күплəр шулай эшли һəм бу Раббыбыз нигъмəтлəреннəн дөрес файдаланмау булып тора.

Кич белəн салатларга, җилəк-җимеш, яшелчəлəргə басым ясарга, ə иртəн ботка, кипкəн җимеш һəм чиклəвеклəр ашарга киңəш ителə.

Кеше үзгəрə һəм һəр көнне тоткан уразасы аны үзгəртə. Əгəр ул үзенə җитəрлек дəрəҗəдə генə көненə ике тапкыр ризык кулланса, суны шулай ук җитəрлек дəрəҗəдə эчсə, 7 сəгатьтəн дə кимрəк, 8 сəгатьтəн дə күбрəк йокламаса, физик күнегүлəр ясарга иренмəсə (5-6 чакрымны җəяү йөрсə, йөзү белəн шөгыльлəнсə, җиңелчə йөгерсə), аның тоткан уразалары файдага була. Бирегə иң мөһиме — уразаны Аллаһ ризалыгы өчен дип тоту.

**ЭЛЬВИРА ХƏБИБУЛЛИНА əзерлəде**

# Илгизә Нәзир шигырьләре

## МӨБАРӘК БУЛ, И, ИЗГЕ РАМАЗАН!

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
Рамазан ул – мәгърифәтнең
якты нуры,
Рамазан ул – савап,
рәхмәтләрнең ае,
Рамазан ул – гөнаһларны ярлыкаучы,
Изге гамәл, яхшылыклар кылу ае.
Рамазан ул җәннәт ишекләрен ача,
Рамазан ул җәһәннәмгә юлны яба.
Олуг Китап – Коръән-Кәрим
укый-укый,
Мөселманнар җаннарына шифа таба.
Рамазанда мең айдан да Кадерлерәк,
Хәерлерәк, асыл, затлы бер кичә бар.
Зекер әйтә,тәсбих тарта, намаз укый
Ун тән буе уяу булып калучылар.
Изге Күктән Аллаһыбыз безгә дәшә:
“ Рамазан ул – уразаның айларыдыр.
Рамазан ул – калебләрне
чистартучы,
Саклаучы да, тугрылаучы,
яклаучыдыр.
Рамазан ул – гадел хөкем айлары да,
Рәсүлегез Мөхәммәдне данлау ае.
Рамазан ул – үз-үзеңне җиңү ае.
Коръән белән булыр
тормышыгыз җае.
Сез минем каршымда – барыгыз
бертигез!
Мөселман-мөэминнәр, аңлагыз,
белегез!
Дус –туган булыгыз, берләшеп
яшәгез!
Хатасыз бәндә юк, кичерә белегез!”
Рамазан ул – изге, нурлы,
моңлы айдыр,
Күп мактаулар һәм
данлаулар бит Аңарга!
Раббыбыз өчен, дип,
ураза без тотыйк,
Язмасын безләргә тәмугта янарга!
Намазларга дәшеп яңгырыйдыр азан –
Матур тавыш, мәкам үзе лә ни тора!
Каткан күңелләребезне
дә йомшартып,
Мәчет якларына бүген ул бит бора.
Бул мөбарәк, иң саваплы,
иң җаваплы
Аебыз ла безнең, и, изге Рамазан!
Аллаһ йортларына килеп,
җыйнаулашып,
Догаларны кылыйк,
мөкатдәс Рамазан!
Рамазан ул – акыл, рухыбызның ае,
Җаннарыбызны без
пакьлик һәм сафлыйк.
Күңелләрне нурга төреп,
күркәм яшик,
Иманыбызда без мәңгелеккә калыйк!
Хәер-сәдәкалар бирик мохтаҗларга,
Телик барчабызга, ил-көнгә бәрәкәт.
Авыз ачтыруның сөннәт икәнен дә
Онытмаска кирәк, хөрмәтле җәмәгать.
Рәхим-шәфкать безгә
һәрчак юлдаш булсын,
И, мөселман, газиз
туган-кардәшләрем!
Йомшак, җылы сүзне –
җан азыгын, зинһар,
Кызганмыйк бер-беребезгә,
диндәшләрем!
Рамазан – ул бар айларның
солтаныдыр!

## РӘХМӘТ СИҢА, ХАК ТӘГАЛӘМ!

Рәхмәт Сиңа, Хак Тәгаләм минем,
Чыклы иртә, алсу таң өчен,
Алтын кояш, көмеш аем өчен,
Күңелем тулы якты моң өчен.
Рәхмәт Сиңа, газиз Аллам минем,
Җылы җәйләр, ап-ак кыш өчен,
Ләйсән яңгыр яуган язлар өчен,
Бәхеткә тиң алтын көз өчен.
Рәхмәт Сиңа, и Ходаем минем,
Чишмә биргән көмеш су өчен.
Урманнарым, тугайларым өчен,
Сулар һавам, имин көн өчен.
Рәхмәт Сиңа, и Аллаһым, Раббым,
Гөл-чәчәкләр җирдә бар өчен.
Газиз әнкәм, якыннарым өчен,
Изге нигез, туган йорт өчен.

## ДӨНЬЯДА БЕЗ – КУНАК КЫНА

Бу дөньяда без тик кунак кына –
Шуны бүген күпләр аңламый.
Байлык өчен җанын фида кыла,
Артка борылып та карамый.
“Намус” төшенчәсе ят аларга,
Кеше өлешенә керәләр.
Мохтаҗлар бар, ятимнәр күп, алар –
Балда – майда гына йөзәләр.
Нәфес – яман корт ул, туя белми,
Ул кешене гелән котырта.
Күркәм сыйфатларын тартып алып,
Төп башына аны утырта.
Байлык, акча белән түгел дөнья –
Игелекле гамәл, эш белән.
Чиста күңел, якты хисләр безгә
Ходай тарафыннан бирелгән.
Рәнҗетмикче без бер-беребезне,
Алтын-көмешләргә табынмыйк!
Асыл, затлы кыйммәтләр бар җирдә,
Шуларга без ныграк тотыныйк!

## САБЫРЛЫК БИР, РАББЫМ АЛЛАҺЫМ!

И Аллаһым, Ходам, Раббым минем!
Әллә чынлапмы соң яратасың?!
Бер өзлексез мине сыныйсың Син,
Чәчләремне һаман агартасың.
И, йөрәгем, ничек түзәсең син?
Шулкадәрле түзүләрең каян?!
Берсе арты берсе – сынауларың,
Әйтерсең лә, чагып тора чаян.
“Тынычлык бир җаннарыма!” – диеп,
Инәлепләр сорыйм, Раббым, Синнән!
“Чыдаганың кадәр генә сыныйм!” –
Дигән җавап ишет тагын Миннән”.
Шулай диеп дәшәсең бит, Хагым!
Ничекләр соң Сиңа карышыйм?
Сабырлыклар бирче, и, Ходаем!
Кыек юлга кертмә, ялгышмыйм.
Утларга да атасың Син мине,
Бозлы суларга да саласың.
Шул рәвешле якынайтып мине
Бөек булып, Раббым, каласың!

---

### Укырга чакырабыз

## Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

**Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2013-2014 уку елына шәкертләр туплавын дәвам итә.**

Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә ир-егетләр кабул ителә (шәһәребездән һәм авыллардан). Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр ашау–эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты–дүрт ел. Урта белем алу икенче лицей нигезендә алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.

**УКЫРГА КЕРҮ ӨЧЕН КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕНӘ ТҮБӘНДӘГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫ ТАПШЫРЫРГА КИРӘК:**

1) Гариза
2) Белем турында таныклык
3) 086-формасында сәләмәтлек турында белешмә
4) Паспорт (копия)
5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосүрәт
6) №26 формасында индивидуаль медицина картасы

Документлар 30 августка кадәр кабул ителә.

Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.

**Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28,
Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.
Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.
Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**